**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2026 елның 6 мае** **44-РС номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елның 28 октябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәренең шәхси мәгълүматлары һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 87-РС нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында»гы 1009 нчы номерлы Указының 4 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елның 28 октябрендәге 87-РС нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәренең шәхси мәгълүматлары һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2.8, 2.9, 2.10 һәм 2.11 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;
2. 4.3пунктында:

а) «у» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«у) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ нче номерлы Федераль законда күздә тотылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрне, һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ нче номерлы Федераль законда күздә тотылган чыгымнар турындагы белешмәләрне;»;
б) «ш» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ш) муниципаль хезмәткәр тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең, шулай ук муниципаль хезмәткәр тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ нче номерлы Федераль законда һәм коррупциягә каршы көрәш максатында башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны саклау, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яки җайга салу һәм бурычларны үтәү таләпләренең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында белешмә, һәм (яисә) хезмәт тәртибенә карата таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия утырышы

беркетмәсенең күчермәсе (беркетмәдән өземтә).»;
3) 4.6 пунктының «г» һәм «д» подпунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4.Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көненнән башлап үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А.Ә. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы –**
**Совет рәисе:** **И.Ф. Зарипов**